| СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 сентября 2016 года с. Новые Чути № 38

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү.

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 февралендә кабул ителгән 70 номерлы «Салих авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын арттыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2016 елның 20 ноябренә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2017 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 200 (ике йөз) сум күләмендә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Хансвер авылы зиратын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу-40800 сум;
- Яңа Чүте авылы зиратын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу-44600 сум;
- Салих авылы зиратын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу-16800 сум;

«ӘЙЕ, »ЮК".

3. Әлеге карар Салих авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш. http://bavly.tatarstan.ru/rus/salihovskoe.htm.
Салих авыл җирлегенең Яңа Чүти авылы, авыл җирлеге бинасы, Тукай урамы, 65 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Салих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов